СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422701 Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Высокая Гора, ул. Б.Красная, 113 А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИЕКТАУАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422701, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау авылы, Зур Кызыл урамы, 113А йорт

тел./факс 8(84365) 74-7-79, e-mail: Vgor.Vsg@tatar.ru


**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**19.11.2024г.** **№406**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Биектау авылы торак пунктларында гражданнарның үзара салым чараларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 нчы статьяларына, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 нче статьясына, Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Уставының 24 нче статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) таянып, **КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Биектау авылы торак пунктының Радужная, Космонавтов, Руслан Июдин, Михаил Богомолов, Сагдиев, Абтрахим Муртазин урамнары территориясе өлешендә Биектау авылы, Радужная урамы, 78 нче йорт (кибет янында) адресы буенча 2024 елның 2 нче декабрендә 18 сәгать 30 минутта гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Биектау авылы торак пунктының Радужная, Космонавтов, Руслан Июдин, Михаил Богомолов, Сагдиев, Абтрахим Муртазин урамнары территориясе өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2025 елда 5000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, түбәндәге эшләр башкару белән килешәсезме:
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- урамнарны яктырту буенча эшләр;
- торак пункт территориясен төзекләндерү;

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Интернет челтәрендәге рәсми сайтында https://vysokayagora.tatarstan.ru/ адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Биектау авыл җирлеге башлыгы А.А. Хабибуллин